| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.05.2019 ш.т.п Балык Бистәсе № 166пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясе буенча уза торган даими муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурслар оештыру турында» 2015 елның 3 сентябрендәге 235пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Муниципаль норматив хокукый актны законнарга туры китерү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында” һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында 26.12.2015 ел, №107-ТРЗ ТР Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы белән КАРАР БИРӘМ:

1. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясе буенча уза торган даими муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртү хокукына ачык конкурслар оештыру турында» 2015 елның 3 сентябрендәге 235пи номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) карарның преамбуласында «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында 2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасында пассажирлар йөртүне оештыру турында» 2006 елның 13

ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында» 2008 елның 21 октябрендәге XXXIII-5 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары, тормышка ашырыла торган автомобиль һәм шәһәр җир өсте территориясендә гомуми файдаланудагы Татарстан Республикасы» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясе буенча уза торган даими муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга кертү тәртибе турында нигезләмәнең 1.1 пунктында «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында «2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы», «Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында «2006 елның 13 ноябрендәге 70-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру хакында» 2008 елның 21 октябрендәге XXXIII-5 номерлы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне оештыру турында"сүзләрен төшереп калдырырга:

1.3) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясе буенча уза торган даими муниципаль маршрутлар буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыруга кертү тәртибе турында Нигезләмәнең 1.4 пунктында «,кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары В. И. Токрановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов